| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 май 2021 ел № 3111

Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5916 номерлы карары белән расланган суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 октябрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булган хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте тулысынча булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау, исәпкә алу һәм әзерләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалтуны тану турында» 2020 елның 30 октябрендәге 2361 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 1 октябрендәге 5916 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 3 октябрендәге 5907 номерлы, 2018 елның 14 ноябрендәге 6683 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган суд тәртибендә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затка опека яки попечительлек билгеләү һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Бүлек бүлмәләрендә урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша:

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында (https://mon.tatarstan.ru/rus/), Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://nabchelny.ru/);

- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

- Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Бүлеккә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Бүлеккә язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәккә (алга таба – КФҮ) мөрәҗәгать иткәндә.»;

2) 1.4 пунктта:

- унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.07.2015 № 29 (I өлеш), ст. 4344);

- 20 абзацта «2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы» сүзләрен «2020 елның 25 февралендәге 101-р номерлы» сүзләренә алмаштырырга»;

- түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 27 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 181-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 27.11.1995, № 48, ст. 4563).»;

3) 2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге | Гариза бирүчеләр (опекун булырга теләк белдергән якын туганнардан тыш) яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>1) гариза (3 нче кушымта);<br>2) гражданны хокукка сәләтсез (хокукка сәләте чикләнгән) дип тану турында суд органының законлы көченә кергән карары;<br>3) эш урыныннан соңгы 12 ай өчен вазыйфасы һәм уртача хезмәт хакы күләме күрсәтелгән белешмә, ә хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган гражданнар өчен-керемнәрне раслаучы башка документ (пенсионерлар өчен – пенсия таныклыгының күчермәләре, Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органыннан яки пенсия белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы башка органнан белешмә);<br>4) балигъ булган опекага алынучының инвалидлык турында белешмәсе (билгеләнгән үрнәктәге) (булганда) һәм аны тернәкләндерүнең медицина-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан бирелгән индивидуаль программасы;<br>5) опекун булырга теләк белдергән граждан белән бергә яшәүче гаиләнең балигъ булган әгъзаларының, 10 яшькә җиткән балаларның фикерен дә исәпкә алып, балигъ булган опекага алынган затның опекун белән | РФ Граждан кодексы;<br>РФ Салым кодексы;<br>48-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>927 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| | бергә яшәвенә язмача ризалыгы (опекун тарафыннан балигъ булган опекага алынган затның опекун гаиләсе белән бергә яшәве турында карар кабул ителгән очракта), шулай ук кайда яшәүләренә карамастан, опекага алынган затның якын туганнарының (ата-анасының, кыз һәм ир туганнарының) ризалыгы (гариза рәвешендә);<br>6) опекага алынган затның мөлкәте турында (торак, автотранспорт, кыйммәтле кәгазьләр, саклык счетлары һ.б. турында) мәгълүматлар;<br>7) автобиография.<br>Опекун булырга теләк белдергән якын туганнар яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына түбәндәге документларны тапшыралар:<br>10) гариза (3 нче кушымта);<br>11) балигъ булган опекага алынган зат белән туганлыкны раслаучы документлар.<br>* 3 пунктчада каралган документлар алар бирелгән көннән башлап бер ел эчендә кабул ителә. | |

4) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | - «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФДССУның Яр Чаллы шәһәре буенча (алга таба – ТР буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге) шәһәр (район) филиалының торак биналарның санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килүе турында бәяләмәсе;<br>- эчке эшләр органнарының опекун (попечитель) булырга теләк белдергән гражданның граждannар тормышына һәм сәламәтлегенә карата аңлы рәвештә җинаять кылган өчен хөкем ителмәвен раслаучы белешмәсе;<br>- эчке эшләр органнарыннан РФ гражданын яшәү урыны буенча теркәү турында мәгълүматлар;<br>- ГХАТ идарәсе МКУдан язылышу турында таныклык күчермәсе (әгәр опекун булырга теләк белдергән якын туганы язылышкан булса);<br>- опека һәм попечительлек балигълык яшенә җитүгә бәйле билгеләнгән очракта, опекун булырга теләк белдергән якын туганның опекага алынучы белән ул 18 яшькә җиткәнчегә кадәр тиешенчә мөрәҗәгать | 927 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| | итмәү фактлары булмау турында опека һәм попечительлек органнары бәяләмәсе. Опека һәм попечительлек органында әлеге мәгълүматлар булган очракта ведомствоара запрос җибәрелми. | |

5) 2.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | 1) дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 12 пункты,<br>181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- дәүләт хезмәте күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов